**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

2020 елның 1 октябре № 18

Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2015 елның 27 маенда кабул ителгән 22 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2015 елның 27 маенда кабул ителгән 22 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә, 2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «Башкарма комитетның урнашу урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы , 29 Б.»

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге Советының 2020 елның 01 октябрендәге 18 номерлы карарына кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМӘШИР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең (алга таба – Авыл җирлеге) башкарма-боеру функцияләрен башкаручы җирле үзидарә органы булып тора.

1.2. Башкарма комитет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актларына, Кукмара муниципаль районының, Җирлекнең норматив-хокукый актларына, Җирлек Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Башкарма комитет Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авыл җирлеге территориясендә үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, территориаль федераль башкарма хакимият органнары, Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә башкара.

## 2. Юридик статус

2.1. Башкарма комитет юридик зат булып тора.

2.2. Башкарма комитетның исеме язылган мөһере, штамплары, бланклары, Россия Федерациясе законнары нигезендә банк учреждениеләрендә исәп-хисап һәм башка счетлары бар. Башкарма комитет мөлкәт һәм милек булмаган хокукларны һәм бурычларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта гариза бирүче яки җавап бирүче булып чыгыш ясарга хокуклы, мөстәкыйль балансnúmка ия.

2.3. Башкарма комитетның урнашкан урыны: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Мәмәшир авылы, Яшьләр урамы, 29 Б.

## 3. Башкарма комитетның төп бурычлары һәм функцияләре

3.1. Башкарма комитет җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен, шулай ук килешүләр нигезендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча бурычларны тормышка ашыруны оештыра.

3.2. Авыл җирлеге башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- җирлек бюджеты проектын, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программалары проектларын эшли;
- җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программаларының үтәлешен оештыра;
- җирлек бюджеты үтәлеше турында хисап, җирлекнең комплекслы социаль-икътисади үсеш программаларының һәм планнарының үтәлеше турында хисап әзерли;

- җирлекнең икътисад һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милек белән идарә итү, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәте белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, куллану, алар белән эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- җирлек Советы карары белән билгеләнгән очракларда, җирлек Советы килешүенә (раславына) муниципаль милекне читләштерү, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәр әзерли һәм кертә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән җирлекнең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек итү турында килешүләр төзи; җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр булдыруга ярдәм итә;

- җирлек Советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, алар эшчәнлегенең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә аларның җитәкчеләрен билгели һәм биләп торган вазыйфадан азат итә;

- муниципаль заказ формалаштыра һәм урнаштыра; муниципаль биремне бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс ягыннан тәэмин итә; җирлекне төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм ремонтлау, продукция җитештерү, халыкның көнкүреш һәм социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү, моның өчен каралган үз матди һәм финанс чараларыннан файдаланып башка эшләр башкаруга заказ бирә;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;

3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә:

- Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирлекнең генераль планы проектын һәм җирлекнең башка шәһәр төзелеше документациясе проектларын җирлек Советына раслауга әзерли һәм кертә, аларның үтәлешен тәэмин итә;

- халыкка экологик хәл турында хәбәр итә, тиешле органнарга әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турындагы законнарны бозучы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның эш-гамәлләре турында хәбәр итә;

4) төзелеш, транспорт һәм элемтә өлкәсендә:

- билгеләнгән тәртиптә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алып бара;

- билгеләнгән тәртиптә торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак биналарга күчерү турында карар кабул итә, торак биналарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль торак фондының торак урыннарын яшәү өчен яраксыз дип таный;

- җирлектә яшәүче һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак законнары нигезендә торак урыннары белән тәэмин итә;

- муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны, торак төзелеше өчен шартлар булдыруны оештыра;

- муниципаль торак фондыннан файдалану һәм сакланышы, әлеге фондның торак биналарының санитар һәм техник кагыйдәләр һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;

- халыкны элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;

5) авыл хуҗалыгын һәм эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендә:
- авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;

6) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:
- җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су бүлүне, халыкны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә ягулык белән тәэмин итүне оештыра;
- халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базарлар һәм ярминкәләр оештыра;
- халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне, җирлек китапханәләренең китапханә фондларының сакланышын тәэмин итүне һәм комплектлауны оештыра;
- халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тудыра, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;
- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм тормышка ашыра;
- транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын һәм җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшли һәм тормышка ашыра;
- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны гамәлгә ашыра, муниципаль берәмлек чикләрендә биналары муниципаль торак фонды булган күп фатирлы йортларга энергетика тикшерүен үткәрүне оештыра, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган башка чараларны оештыра һәм үткәрә;
- «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда каралган җылылык белән тәэмин итүне оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;
- «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» Федераль законда каралган су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;
- коммуналь инфраструктура системасына тоташуга тарифларны, коммуналь комплекс оешмаларының тоташуга тарифларын, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларга өстәмәләрне, кулланучылар өчен бәяләргә (тарифларга) өстәмәләрне җайга сала.

7) төзекләндерү өлкәсендә:
- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыра;
- урамнарны яктыртуны һәм урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр урнаштыруны оештыра;

8) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:
- җирлек территориясендә законнар, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актлары үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;
- билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судта, җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хокукларын боза торган актларына карата шикаять бирә;
- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;

9) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:
- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

10) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;
- дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс чараларын исәпкә алып бара һәм тиешенчә файдалануны тәэмин итә;
- федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра;

11) оборона, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендә:
- үз компетенциясе кысаларында хәрби идарә органнары белән үзара бәйләнештә торып, оборона һәм авыл җирлеге өлкәсендәге законнарның үтәлешен тәэмин итә;
- эшчәнлеге күрсәтелгән органнар эшчәнлеге белән бәйле яисә алар карамагында булган башкарма комитет һәм оешмаларның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра, тәэмин итә һәм аңа җитәкчелек итә;

12) башка вәкаләтләр:
- җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны, «Федераль милектә булган су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрүне тәэмин итә»;
- Җирлек башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан тәэмин итүне башкара;
- җирлекнең архив фондларын формалаштыруны тәэмин итә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында, гражданнарны җирлек өчен әһәмиятле булган әлеге Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенең 4, 6 һәм 9 пунктларында каралган социаль әһәмиятле эшләрне (шул исәптән дежурлыкларны) ирекле нигездә башкаруга җәлеп итү турында карар кабул итә һәм аларны үткәрүне оештыра;
-муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектларын тикшерү, муниципаль берәмлек халкына муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый һәм мәдәни үсеше, аның иҗтимагый инфраструктурасын үстерү турында һәм башка рәсми мәгълүматны җиткерү өчен, массакүләм басма мәгълүмат чарасын гамәлгә куя;
- федераль законнар нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра;
- ритуаль хезмәтләр оештыруны һәм күмү урыннарын карап тотуны гамәлгә ашыра;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча, ззаконнар, әлеге Устав, җирлек Советы карарлары белән җирлек Советы яисә башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән вәкаләтләрдән тыш, башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3. Башкарма комитет җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:
- җирлек музейлары булдыра;
- җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр башкара;
- опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнаша;
- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;
- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга ярдәм итә;
- җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;
- муниципаль янгын сагы булдыра;
- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;
- кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтә.

- инвалидлар иҗтимагый берләшмәләренә һәм шулай ук «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре оештырган оешмаларга ярдәм күрсәтә;
- федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәя бирүне оештыру өчен шартлар тудыра;
- тораксоциаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирә.

3.4. Җирлекнең башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә Авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) тиешле эшчәнлек өлкәләрендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру һәм уздыру, аны уздыру күрсәткечләре һәм методикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре, мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә, Җирлек башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## 4. Җирлекнең Башкарма комитеты тарафыннан хәл ителә торган Җирлекнең җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләре

Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча Авыл җирлеге башкарма комитеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:
- Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны электр һәм су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;
- җирлек халкына массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керүен тәэмин итү».

## 5. Авыл җирлеге башкарма комитеты

5.1. Авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы булып тора.

5.2. Авыл җирлеге Башкарма комитетының рәсми атамасы –
«Мәмәшир авыл җирлеге башкарма комитеты».

5.3. Авыл җирлеге башкарма комитеты авыл җирлеге Советына хисап тота һәм контрольдә тотыла.

5.4. Җирлек башкарма комитетының җирлек гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган мөһере, бланклары, шулай ук, нотариаль гамәлләр кылу өчен, Россия Федерациясе гербы сурәте төшерелгән түгәрәк мөһере бар.

5.5. Җирлекнең башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## 6. Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру

6.1.Башкарма комитетның структурасы Җирлек башлыгы тәкъдиме буенча Җирлек Советы тарафыннан раслана.

6.2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына түбәндәгеләр керә: Башкарма комитет җитәкчесе – Җирлек Башлыгы, Башкарма комитет секретаре, Башкарма комитетның башка вазыйфаи затлары.

## 7. Хезмәт мөнәсәбәтләре

7.1. Башкарма комитетта хезмәт итү – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башкарыла торган муниципаль хезмәт. Башкарма комитетта муниципаль вазыйфаларда хезмәт итүче затлар муниципаль хезмәткәрләр булып торалар.

7.2. Башкарма комитет һәм муниципаль хезмәткәрләр (муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль хезмәткәр булмаган техник хезмәткәрләр) арасындагы мөнәсәбәтләр хезмәт законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән җайга салына.

7.3. Башкарма комитет һәм ведомство карамагындагы учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләре арасындагы мөнәсәбәтләр хезмәт законнары, граждан законнары, әлеге Нигезләмә, алар белән төзелгән хезмәт шартнамәләре белән җайга салына.

7.4. Башкарма комитет хезмәткәрләренең хезмәт хакы законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

7.5. Башкарма комитет Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган хезмәтне саклау чараларын гамәлгә ашыра һәм законнарда билгеләнгән җаваплылык тота.

## 8. Башкарма комитетының мөлкәт һәм финанс эшчәнлеге

8.1. Башкарма комитет әлеге максатларга җирлек бюджетында каралган акчалар чикләрендә чыгымнар сметасы нигезендә, шулай ук законнар белән тыелмаган башка чыганаклар хисабына финанслана.

8.2. Башкарма комитетның финанс һәм икътисади нигезен түбәндәгеләр тәшкил итә: Җирлек бюджеты, акчалары, Башкарма комитет карамагына тапшырылган функцияләрне тәэмин итү өчен булдырылган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр, шулай ук идарә функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитетка тапшырылган башка муниципаль мөлкәт.

## 9. Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртеп кору

Башкарма комитетны бетерү һәм үзгәртеп кору федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Җирлекнең җирле үзидарә органнарының норматив актларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.